ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.11.2025 с. Введенская Слобода №6

«Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Балалар шифаханәсе бистәсендә гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 15 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Балалар шифаханәсе бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Балалар шифаханәсе бистәсендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:
- урамнарны яктыртуны җайлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Балалар шифаханәсе бистәсе, Дубравная урамы адресы буенча 10:00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов